МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 139/о

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

«__11___»____09_____2023

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 151/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2021 елның 30 сентябрендәге 151/о номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 7 ноябрендәге 152/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь

хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **М.М.Айзатуллин**

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК МИНИСТРЛЫГЫ * Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалык министрлыгының «11»
09 2023ел, № 139/о боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 151/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.1 пунктның беренче абзацында «шул исәптән эксперт ярдәме» сүзләрен «шул исәптән инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә кертелгән үзгәрешләр һәм проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсен алган проект документациясенә кертелгән үзгәрешләр (шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлешендә каралмаган үзгәрешләр) буенча эксперт ярдәме» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Гариза, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән документларны, шул исәптән мәгълүмати модельләштерү технологияләрен кулланып эшләнгән проект документациясен (ТИМ-технологияләр) кушып, «Бердәм цифрлы экспертиза платформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, электрон рәвештә тутырыла.»

2.6.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1.1. Бер үк вакытта проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә кертелгән үзгәрешләрнең дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсенә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^9$ өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү өчен (алга таба – эксперт ярдәме кысаларында туры килүне бәяләү), эксперт ярдәме кысаларында, түбәндәгеләр тапшырыла:

а) проект документларының үзгәрешләр кертелгән бер өлеше;

б) проект документларына кертелгән үзгәрешләр тасвирламасы белән белешмә;

в) төзүче яисә техник заказчының проектлау биреме (аңа үзгәрешләр кертелгән очракта);

г) проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;

д) үзгәрешләр кертелгән инженерлык эзләнү нәтиҗәләре (инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертелгән очракта)

е) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә кертелгән үзгәрешләрне тасвирлаган белешмә;

ж) инженердык эзләнүләрен башкаруга йөкләмә (аңа үзгәрешләр кертелгән очракта).»;

2.6.1.2 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) эксперт ярдәме барышында проект документациясенә кертелгән үзгәрешләр нәтиҗәсендә капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең смета бәясе үзгәрсә һәм дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектына карата билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре бирү турындагы карарда билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү хакына туры килмәсә, – эксперт ярдәме нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү турында гариза, анда эксперт ярдәме кысаларында бирелгән бәяләмәләрнең туры килүен бәяләү нәтиҗәләре турында, бирелгән бәяләмәдә төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $8^3$ статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән очракларда Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклап калу эшләренең смета бәясен (алга таба – смета бәясен тикшерү) билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә чагылыш табуның кирәклеге турында мәгълүмат, Нигезләмәнең 13 пунктындагы «а» пунктчасының унберенче – унбишенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүмат, проект документациясенә һәм (яисә) инженер эзләнү нәтиҗәләренә кертелгән эшләрнең физик күләмнәрен, конструктив, оештыру-технологик һәм башка хәл ителешләрне үзгәртү нәтиҗәсендә кертелгән өлешендә капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә расланган смета нормативларын, федераль берәмлек бәяләрен исәпкә алып төзәтелгән, шул исәптән эксперт ярдәме нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү турында гариза бирелгән көнгә алар турында мәгълүмат арадаш нормативларның федераль реестрына кертелгән смета нормаларына, һәм (яисә) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән төзелеш ресурсларының смета бәяләренә карата аерым өлешләре буенча смета күрсәтелә, Нигезләмәнең 13 пунктындагы «л(4)» пунктчасында каралган карар яки, әлеге карар һәм Нигезләмәнең 13 пунктының «а» пунктчасының унберенче – унбишенче абзацларында күрсәтелгән белешмәләр булмаган очракта, – Нигезләмәнең 13 пунктындагы «л(7)» һәм «п» пунктчаларында каралган документлар.»;

2.8 пунктның «г» пунктчасында «проект документациясе» сүзләреннән соң «һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре» сүзләрен өстәргә;

3.7 пунктның өченче абзацында «№1, №1.1 кушымтада» сүзләрен «№1 кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе мөрәҗәгать итүчедән проект документларында кулланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләрнең исәпләмәләрен, инженерлык эзләнү материалларын, шулай ук Нигезләмәнең 13 пунктындагы «а» пунктчасының унберенче-унбишенче абзацларында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыруы турында өстәмә таләп итәргә хокуклы. Әлеге исәпләмәләр, материаллар һәм мәгълүматлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле таләп алынганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.»

бишенче абзацта «биш эш» сүзләрен «3 эш» сүзләре белән алыштырырга;

3.9.1.1 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.9 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең әйдәп баручы эксперты тугыз эш көне дәвамында проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең тәңгәллеген бәяли. Әгәр инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә үзгәрешләрнең туры килүен бәяләүгә бер үк вакытта проект документациясенә үзгәрешләр һәм (яисә) туры килүен бәяләүгә тәкъдим ителә торган проект документларына үзгәрешләр проект документациясенең 2 һәм аннан да күбрәк бүлегенә кертелгән очракта, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан әлеге срок озайтыла ала, әмма иң күбе 10 эш көненә кадәр генә.

Эксперт ярдәме нәтиҗәсе булып бәяләмә тора:

а) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә туры килүен раслау (уңай бәяләмә) яки расламау (тискәре бәяләмә) турында;

б) проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитар-эпидемиологик таләпләргә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсе таләпләренә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз файдалану таләпләренә, сәнәгый куркынычсызлык таләпләренә, электр энергиясе системаларының һәм электр энергиясе объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата таләпләргә, объектның террорчылыкка каршы яклану таләпләренә, төзүченең яки техник заказчының проектлау биременә, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлешенә ярашлы булуын да кертеп, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүен (уңай) яки туры килмәвен (тискәре) раслау турында.

Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алганнан соң смета нормативлары, аерым бәяләр, шул исәптән смета нормаларына карата аларның аерым өлешләре, алар турындагы мәгълүмат смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета бәяләрен үзгәртү индекслары, төзелеш ресурсларының хәзерге дәрәҗәдә һәм (яки) 2022 елның 1 гыйнварына булган

торышындагы бәяләр дәрәҗәсендә смета бәяләре, төзелештә бәяләр куюның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган бер төрле төзелеш ресурслары төркемнәре буенча исәпләнгән смета бәясен исәпләгәндә исәпкә алынган смета бәясен үзгәртү индекслары үзгәрсә, смета бәясен кабат тикшерү өчен документлар тапшыру, смета нормативларының смета бәясен кабат тикшерү өчен документлар тапшыру датасына гамәлдә булган документларны, аерым исәпләмәләрне, шул исәптән смета нормаларына карата аларның аерым өлешләрен, алар турындагы мәгълүмат смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета бәяләрен үзгәртү индексларын, төзелештә бәяләр куюның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган бер төрле төзелеш ресурслары төркемнәре буенча исәпләнгән смета бәясен исәпләгәндә исәпкә алынган смета бәясен үзгәртү индексларын исәпкә алып, проект документациясендә каралган эшләрнең физик күләмнәрен, конструктив, оештыру-технологик һәм башка чишелешләрне үзгәртү нәтиҗәсендә үзгәрешләр кертелгән өлештә смета документациясен корректировкалаганнан соң гамәлгә ашырыла, бу вакытта смета документациясенең калган өлеше корректировкаланмый.

Әгәр беренчел дәүләт экспертизасын үткәргәндә базис-индекс ысулы кулланылса, смета бәясен кабат тикшерү уздыру өчен яңадан дәүләт экспертизасын уздыру өчен документлар тапшыру датасына гамәлдә булган смета нормативларын, аерым исәпләмәләрне, шул исәптән смета нормаларына карата аларның аерым өлешләрен, алар турындагы мәгълүмат смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета бәяләрен үзгәртү индексларын кулланып төзелгән смета документациясе җибәрелә.

Бәяләүне үткәргәннән соң, бәяләмә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең әйдәп баручы эксперты тарафыннан, раслау, теркәү һәм мөрәҗәгат итүчегә бирү өчен, эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсенә җибәрелә.

Бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмәне раслау, теркәү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү бер эш көне дәвамында башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 2.6.1.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләү нәтиҗәләре буенча теркәлгән бәяләмәне мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.»;

1 нче кушымтада 6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4. Әлеге шартнамәнең 6.3 пунктында күрсәтелгән шартлар килеп чыкканда, Башкаручы Заказчыга әлеге шартнамәне үтәүдән баш тарту (шартнамәне өзү) турында тиешле язма хәбәр җибәрә. Белдерү Заказчыга китерелгән вакыттан башлап, шартнамә өзелгән булып санала.»

Административ регламентка 1.1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Административ регламентка 4 нче кушымтада:

I бүлегендә:

9, 10, 12-15, 17 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

17.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.1 әлеге бүлекнең 16 пунктында күрсәтелгән карар һәм Нигезләмәнең 13 пунктының «а» пунктчасының унберенче-унбишенче абзацларында күрсәтелгән карарлар (актлар) турында белешмәләр булмаган очракта, шул исәптән мондый карарлар (актлар) рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиешле булмауга бәйле рәвештә дә, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүнең проект документларында күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета яки күзалланган (чик) бәяне арттырып җибәрсә, – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 процenttан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисенең (Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты билгеләгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 процenttан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, муниципаль бюджетлар акчалары хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен, шулай ук финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге, шул исәптән төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау әлеге юридик затларның акчалары хисабына планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектлары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан төзелгән, үзгәртеп корылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне

раслый торган, капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны финанслау буенча бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотыла торган чыганаклар яисә бюджетка карамаган чыганаклар турында мәгълүматны үз эченә алган хаты;»;

18 пунктны көчен югалткан дип танырга;

19 нчы пунктта «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе белән вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты)» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе (Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе урынбасары)» сүзләренә алмаштырырга;

20, 21 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 22 пункт өстәргә:

«22. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

II бүлектә:

8, 9, 11, 12 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

III бүлекнең 5, 6, 8 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

IV бүлектә:

9, 10, 12-15, 17 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

17.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.1 әлеге бүлекнең 16 пунктында күрсәтелгән карар һәм Нигезләмәнең 13 пунктының «а» пунктчасының унберенче-унбишенче абзацларында күрсәтелгән карарлар (актлар) турында белешмәләр булмаган очракта, шул исәптән мондый карарлар (актлар) рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиешле булмауга бәйле рәвештә дә, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүнең проект документларында күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета яки күзалланган (чик) бәяне арттырып җибәрсә, – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен) яисә Россия

Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисенең (Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты билгеләгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, муниципаль бюджетлар акчалары хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен, шулай ук финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге, шул исәптән төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау әлеге юридик затларның акчалары хисабына планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектлары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан төзелгән, үзгәртеп корылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне раслый торган, капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны финанслау буенча бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотыла торган чыганаклар яисә бюджетка карамаган чыганаклар турында мәгълүматны үз эченә алган хаты;»;

18 нче пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

19 нчы пунктта «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе белән вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты)» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе (Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе урынбасары)» сүзләренә алмаштырырга;

23, 24 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 25 пункт өстәргә:

«25. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

V бүлектә:

8, 9, 11, 12, 13, 14, 16 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

16.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.1 әлеге бүлекнең 15 пунктында күрсәтелгән карар һәм Нигезләмәнең 13 пунктының «а» пунктчасының унберенче-унбишенче абзацларында күрсәтелгән карарлар (актлар) турында белешмәләр булмаган очракта, шул исәптән мондый карарлар (актлар) рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиешле булмауга бәйле рәвештә дә, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүнең проект документларында күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета яки күзалланган (чик) бәяне арттырып җибәрсә, – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисенең (Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты билгеләгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, муниципаль бюджетлар акчалары хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен, шулай ук финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге, шул исәптән төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау әлеге юридик затларның акчалары хисабына планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектлары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан төзелгән, үзгәртеп корылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне

раслый торган, капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны финанслау буенча бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотыла торган чыганаклар яисә бюджетка карамаган чыганаклар турында мәгълүматны үз эченә алган хаты;»;

17 пунктны көчен югалткан дип танырга;

18 нче пунктта «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе белән вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты)» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе (Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе урынбасары)» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. проект документларын типик проект документларыннан файдаланып әзерләгән очракта, шулай ук документлар тапшырыла:

кулланыла торган бер төр проект документациясенә карата экспертизаның уңай бәяләмәсе һәм дәүләт экспертизасына тәкъдим ителгән проект документациясенең үзгәрешләргә дучар ителмәгән бүлекләре күрсәтелгән белешмә һәм бер төр типовой проект документациясенә тулысынча туры киләләр;

проектлана торган капиталь төзелеш объектын билгеләнешенең һәм проект егәрлегенең аналогик булуын һәм мондый капиталь төзелеш объектын төзүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориядәге табигый һәм башка төр шартларның капиталь төзелеш объектының билгеләнешенә һәм проект егәрлегенә һәм беренчел куллану өчен әзерләнгән, проектлау өчен кулланылган типик проект документларында исәпкә алынган территория шартларына туры килүен раслый торган документ;»;

21, 22 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 23 пункт өстәргә:

«23. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

VI бүлектә:

6, 7, 9, 10 нчы пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге 11-12 пунктлар белән тулыландырырга:

«11. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

12. проект документларын типик проект документларыннан файдаланып әзерләгән очракта, шулай ук документлар тапшырыла:

кулланыла торган бер төр проект документациясенә карата экспертизаның уңай бәяләмәсе һәм дәүләт экспертизасына тәкъдим ителгән проект документациясенең үзгәрешләргә дучар ителмәгән бүлекләре күрсәтелгән

белешмә һәм бер төр типовой проект документациясенә тулысынча туры киләләр;

проектлана торган капиталь төзелеш объектын билгеләнешенең һәм проект егәрлегенең аналогик булуын һәм мондый капиталь төзелеш объектын төзүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориядәге табигый һәм башка төр шартларның капиталь төзелеш объектының билгеләнешенә һәм проект егәрлегенә һәм беренчел куллану өчен әзерләнгән, проектлау өчен кулланылган типик проект документларында исәпкә алынган территория шартларына туры килүен раслый торган документ;»

VII бүлектә:

7, 8, 10-13, 15 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

15.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.1 әлеге бүлекнең 14 пунктында күрсәтелгән карар һәм Нигезләмәнең 13 пунктының «а» пунктчасының унберенче-унбишенче абзацларында күрсәтелгән карарлар (актлар) турында белешмәләр булмаган очракта, шул исәптән мондый карарлар (актлар) рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиешле булмауга бәйле рәвештә дә, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүнең проект документларында күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета яки күзалланган (чик) бәяне арттырып җибәрсә, – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 процenttан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисенең (Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты билгеләгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 процenttан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, муниципаль бюджетлар акчалары хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен, шулай ук

финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге, шул исәптән төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау әлеге юридик затларның акчалары хисабына планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектлары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан төзелгән, үзгәртеп корылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне раслый торган, капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны финанслау буенча бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотыла торган чыганаклар яисә бюджетка карамаган чыганаклар турында мәгълүматны үз эченә алган хаты;»;

16 пунктны көчен югалткан дип танырга;

17 нче пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе белән вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты)» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе (Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе урынбасары)» сүзләренә алмаштырырга;

17 нче пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

18-19 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

VIII бүлектә:

5, 10 нчы пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

IX бүлектә:

5, 6 нчы пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

7 нче пунктта «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе белән вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты)» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе (Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе урынбасары)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

X бүлектә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. проектның баш инженеры имзалаган белешмә, анда проект документациясенә кертелгән үзгәрешләр һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре тасвирлана;»;

12, 14-17, 19 нчы пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

19.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.1 әлеге бүлекнең 18 пунктында күрсәтелгән карар һәм Нигезләмәнең 13 пунктының «а» пунктчасының унберенче-унбишенче абзацларында күрсәтелгән карарлар (актлар) турында белешмәләр булмаган очракта, шул исәптән мондый карарлар (актлар) рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиешле булмауга бәйле рәвештә дә, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүнең проект документларында күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета яки күзалланган (чик) бәяне арттырып җибәрсә, – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисенең (Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты билгеләгән вәкаләтләр бүленеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы рәисе урынбасарының), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, муниципаль бюджетлар акчалары хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен, шулай ук финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге, шул исәптән төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау әлеге юридик затларның акчалары хисабына планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектлары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан төзелгән, үзгәртеп корылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне раслый торган, капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны финанслау

буенча бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотыла торган чыганаклар яисә бюджетка карамаган чыганаклар турында мәгълүматны үз эченә алган хаты;»;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе.»;

21 нче пунктта «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе белән вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты)» сүзләрен «Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе (Россия Федерациясе субъекты югары башкарма органы Рәисе урынбасары)» сүзләренә алмаштырырга;

22, 23 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

5 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

5.1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

Административ регламентка кушымтаны (белешмәлекне) яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

Проект документларына һәм
инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
5.1 нче кушымта

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе директорына

Эксперт ярдәме турында түләүле хезмәт күрсәтү шартнамәсен
төзү турында гариза

_______________________________________________ капиталь төзелеш объекты (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау буенча реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, эшләр башкару) буенча эксперт ярдәме турында түләүле хезмәтләр күрсәтү шартнамәсен төзү өчен документлар юллый ____________________________________________________________.

I. Капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре:

а) кузалланган төзелеш (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау буенча реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, эшләр башкару) объектының (объектларының) исеме: _______________________________________;

б) капиталь төзелеш объектының функциональ билгеләнеше турында белешмәләр: 17.4.1.24;

в) капиталь төзелеш объектының (объектларының) почта (төзелеш) адресы: _______________________________________________;

г) капиталь төзелеш объектының (объектларының) төп техник-икътисадый күрсәткечләре (мәйданы, күләме, озынлыгы, катлар саны, җитештерү куәте һәм башкалар): ________________________________

| Күрсәткеч | Күрсәткечнең әһәмияте | Искәрмә |
|---|---|---|
| | | |

д) Капиталь төзелеш объекты урнашкан яисә урнаштыру планлаштырылган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) кадастр номеры: ________________________

II. Эш башкаручылар – проект документациясенә үзгәрешләр әзерләгән затлар турында тәңгәллек белешмәләре:

Башкаручы:

а) юридик затның тулы исеме: __________________;

б) юридик затның урнашу урыны һәм адресы: ______________;

в) юридик затның ИНН ________________;

г) юридик затның ОГРН: _______________;

д) юридик затның КПП: ________________;

е) электрон почта адресы (булган очракта): ______________;

ж) телефоны: ________________;

з) юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы: ______________________________________________________.

Башкаручы:

а) юридик затның тулы исеме: __________________;

б) юридик затның урнашу урыны: ______________________;

в) юридик затның ИНН _________________;

г) юридик затның ОГРН: ________________;

д) юридик затның КПП: _________________;

е) электрон почта адресы (булган очракта): ______________;

ж) телефоны: ______________;

з) юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы: ____________________________________________________.

III. Төзүче, техник заказчы турында тәңгәллек мәгълүматлары:

Төзүче:

а) юридик затның тулы исеме: ______________________;

б) юридик затның урнашу урыны һәм адресы: ______________;

в) юридик затның ИНН: ______________;

г) юридик затның ОГРН: ______________;

д) юридик затның КПП: ________________;

е) электрон почта адресы (булган очракта): ________________;

ж) телефоны: ______________;

з) юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы: ________________________________________.

IV. Мөрәҗәгать итүче турында идентификация белешмәләре:

а) юридик затның тулы исеме: _________________;

б) юридик затның урнашу урыны: __________________;

г) юридик затның ИНН: ____________________________________;

д) юридик затның яисә шәхси эшкуарның ОГРН: _____________________;

ж) юридик затның КПП: _____________;

з) электрон почта адресы (булган очракта): ______________;

и) телефоны: ____________;

к) юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы: ______________________________________.

V. Башка белешмәләр:

Төзүче оешманың вәкаләтләрен капиталь төзелеш объектын төзү (үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләрен) гамәлгә ашыру планлаштырылган җир кишәрлегенә (җир кишәрлекләренә) карата хокуклар турындагы документлар белән раслыйбыз: ______________________.

Югарыда аталган капиталь төзелеш объекты буенча проект документларына карата элегрәк дәүләт экспертизасы уздырылды, аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирелде ___________________________________.

Эксперт ярдәме турында түләүле хезмәт күрсәтү шартнамәсен төзү өчен реквизитлар турында өстәмә хәбәр итәбез:

а) төзүче исеменнән шартнамәгә кул куйган затның реквизитлары:

юридик затның тулы исеме: ____________________;

Шартнамәне имзалаучы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта): ________________________;

төзүче исеменнән шартнамә төзү (имзалау) вәкаләтләрен раслаучы документ: ______________________;

юридик зат урнашкан урын адресы яисә физик затның яшәгән урыны адресы: _________________________________;

клиентның электрон почта адресы (булган очракта): ________________;

оешма, бухгалтерия, шартнамәгә кул куючы затның телефоны/факсы: _____________;

б) төзүче – юридик затның реквизитлары:

Салым түләүченең тәңгәллек номеры________________________________;

Исәпкә алу сәбәбе коды (КПП): _____________________________;

Иң зур салым түләүченең КПП:______________;

Төп дәүләт теркәү номеры____________________;

в) төзүченең банк реквизитлары:

банкның исеме: ___________________________;

исәп-хисап счеты № ___________________________________________;

шәхси счет №: __________________;

БИК: ______________.

Кушымталар: исемлек буенча документлар.

(вазыйфа) (имза) (И.А.и., Фамилия)

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (белешмәлек) кушымта

# ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ХАКИМИЯТ ОРГАННАРЫ (УЧРЕЖДЕНИЕЛӘР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР

## Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр урынбасары | (843) 231-15-07 | Vladimir.Kudryashev@tatar.ru |

## «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | (843) 207-06-04 өстәмә 619 | expertiza-rt@tatar.ru |
| Директорның беренче урынбасары | (843) 222-85-31 өстәмә 401 | Timur.Zinatullin@tatar.ru |
| Директор урынбасары | (843) 222-85-32 өстәмә 402 | I.Ahmetzyanov@tatar.ru |
| Эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсе җитәкчесе | (843) 207-06-04 өстәмә 230 | Guzel.Nugumanova@tatar.ru |
| Экспертиза идарәсе җитәкчесе | (843) 207-06-04 өстәмә 235 | Igor.Alexeev@tatar.ru |

## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестицияләү программаларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |

________________________________________».